# Муртазина Таһирәбану Абдулла кызы.



Бөек Ватан сугышының дәһшәтле һәм фаҗигале көннәре елдан – ел ераклаша бара. Әмма халкыбыз 1418 көн буена дәвам иткән ул коточкыч вакыйгаларны һич тә оныта алмый. Сугышта 27 миллионнан артык совет кешесе һәлак булды, дистәләрчә миллион хатын – кызлар – тол, бик күп балалар ятим калды, инвалидлар биниһая булды. Илебез ярым җимерек хәлгә килде, халкыбыз күпме кайгы – хәсрәт кичерде?!

Авылыбызның хөрмәтле ветеран укытучысы Таһирәбану апа сугыш чоры авырлыклары турында түбәндәге вакыйгаларны сөйләде: “Мин Абдуллина Таһирәбану 1931 нче елның 10 нчы августында Түбән Ушма авылында ура хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килгәнмен. 1939 нчы елда укырга кердем. Шушы елда абыем (1919 елда туган) Хөсәен Совет Армиясенә алынды. Әти-әнием аның китүен бик авыр кичерде . Әти 1940 нчы елда тиф авыруыннан 8 көн генә ятып үлеп китте. Без –әни ,апай (12 нче яшендә ),мин тугызынчы яшемдә ятим калдык ,1941 нче елда сугыш башланды.Шул ук елны абыем сугышка китте. Армиягә кадәр абый Кече Кирмән авылында балалар укытып армиягә алынды , ул бик зыялы кеше, армиядә летчикլыкка укый иде. Хатларында безнең өчен бик борчылып язды: “Әни , сеңлеләремне укытырга тырыш .Сезгә бик авыр инде, мин кайткач барысы да җайланыр,” - дип яза иде.Абый Эстония Тарту шәһәрендә хезмәт итте . Сугышка китәр алдыннан ул безгә посылка салды, анда үзенә бик яхшы эчке киемнәр һәм бик затлы күлмәге һәм әниемә кызыл читле кәшимир яулык , җылы одеал бар иде.

Сугыш вакытында авылда карт-коры һәм балалар гына калды . Үсмер малайлар сыер,үгез җигеп кырда эшләделәр. Халык нык ачыкты. Сугыш 4 елдан артык дәвам итте. Балалар шешенеп ,ачка үлә башлады .Халык җирдәге уләннәр , агач каерылары ,черек бәрәңге ,җирдә калган башак белән көннәр үткәрде. Эшне алып барырга кирәк .Без 11-12 яшьлек балалар кырда ашлык чәчкән урынга билчән утарга йөрдек.Каты җирдә билчән котырып ускән,без нәни кулларыбыз белән аны йолкыйбыз ,куллар каный,күлмәк итәкләре белән тотып йолкыйбыз .

Авылда зур елга бар .Җәй көне шунда тегермән буасы буалар . Бик зур ул. Кем аякта йөри ала, барысы да шунда . Без дә чиләк белән балчык ташыйбыз . Аның өчен безгә кашыклап он бирәләр

15 км ераклыктагы болынга юа (кыргый АРАН) га барабыз , аннан ботка пешерәбез

Өйгә салам ташып ягабыз , өй бик салкын .Тәрәзәләрне каплыйбыз ,чөнки бомба ташучы самолетлар үтәчәк дип хәбәр итәләр.

1943 нче елның 3 нче мартында абыйның үлгән хәбәре килде ,әни бу исәпне күтәра алмыйча урында ятып , җиде айдан вафат булды

Без тырышып укып ,укытучылар булдык .Безне хөрмәтлиләр , 2014 нче елның декабрь аенда әниләр көненә ,иң лаеклы әниләрне –тыл ветераннарын Мамадышка бәйрәмгә чакырдылар .Район җитәкчесе Анатолий Петрович Иванов безгә рәхмәт хаты һәм кыйммәтле бүләк тапшырды .

Еллар имин булсын ,без күргәннәрне киләчәк буыннар күрмәсен.”

Сугыш... Күпме сагыш, кайгы, күз яшьләре алып килдең син! Әйе, Җиңү исәпсез-хисапсыз корбаннар бәрәбәренә яуланды. 70 нче Җиңү язын каршыларга җыенабыз. Тагы күп дистә еллар үтәр. Буын арты буын алмашыр, ләкин Бөек Җиңү һәм шушы җиңүне яулап алган какшамас фронт һәм тыл каһарманнарының якты истәлеге халык күңелендә мәңге яшәр.

*** (Фотода Таһирәбану апа аскы рәттә, уртада.)